**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ БЕССОНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422386 Тетюшский район, с.Бессоново, ул.Стахановская, 12

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БЕССОНОВО АВЫЛ ЖЫРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422386 Тәтеш районы, авыл Бессоново, Стахановская ур, 12

тел. (84373) 51-2-18, факс 8(84373)51-2-18, e-mail: Bson.Tet@tatar.ru
ОКПО 42145341, ОГРН 1021606560029, ИНН/КПП 1638002554/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**10 .12. 2024** **№ 48-1**

**2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджеты турында**

1 Статья

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:
1) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2609,68 мең сум күләмендә;
2) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2609,68 мең сум күләмендә;
3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,00 мең сум күләмендә.
2. 2026 елга һәм 2027 елга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга.:
1) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2026 елга 2717,83 мең сум һәм 2027 елга 2815,71 мең сум күләмендә;
2) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2026 елга 2717,83 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 62,90 мең сум күләмендә, һәм 2027 елга 2815,71 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 130,40 мең сум күләмендә;
3) Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2026 елга 0,00 мең сум һәм 2027 елга 0,00 мең сум күләмендә.
3. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2 Статья

1. 2026 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоновка авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоновка авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.

2. 2027 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоновка авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоновка авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.
3. 2028 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоновка авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,00 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Беденьга авыл җирлеге муниципаль эчке бурычының югары чиген нульле Россия Федерациясе валютасында расларга.
3 Статья

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджетында 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына фаразлана торган керемнәр күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.
4 Статья

1.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.
2.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоновка авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.
3.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2025 елга 0,00 мең сум, 2026 елга 0,00 мең сум һәм 2027 елга 0,00 мең сум күләмендә расларга.
5 Статья

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль учреждениеләргә), индивидуаль эшкуарларга һәм физик затларга – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләрдән тыш) субсидияләр Тәтеш муниципаль районының бессоновка авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә.

6 Статья

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга Тәтеш муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлешендә төзелгән килешүләр нигезендә расларга:
2025 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2026 елга 1,00 мең сум күләмендә;
2027 елга 1,00 мең сум күләмендә.

7 Статья

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджетында Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан алына торган
1) җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр:
2025 елга-2019,40 мең сум күләмендә;
2026 елга - 2108,10 мең сум күләмендә;
2027 елга-2196,40 мең сум күләмендә.
2) территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирле үзидарә органнарына беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга РФ вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр:
2025 елга - 182,98 мең сум күләмендә;
2026 елга - 200,13 мең сум күләмендә;
2027 елга-207,31 мең сум күләмендә.

8 Статья

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2025 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 Статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

10 Статья
Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

11 Статья
Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

12 Статья

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **Ю.А. Врясов**